
# Тәһарәт, тәямүм һәм гөсел алу сыйфатлары 2


## Таһәрат алу тәртибе

Кеше, тәһәрәт алырга ниятләгәннән соң, Аллаһның исеме белән "Бисми-Лләһ" ди; Шуннан соң өч тапкыр кул чукларын юа;



1

Аннан соң уң учына су тутыра, шул суның бер өлешен авызына алып, авыз эчен чайката һәм түкерә; суның калган өлешен борынына суыра, аннан соң аны сеңгерә, сеңгергән вакытта борынын сул кулының баш һәм имән бармаклары белән сыпыра. Шул рәвешле өч тапкыр эшли.




2

Шуннан өч тапкыр битен юа. Битнең чикләре шул: чәчләр үсә башлаган урыннан алып ияк астына кадәр, ә киңлеккә – бер колактан алып икенчесенә кадәр;




3

Аның соңында терсәкләре белән бергә кулларын (бармак очларыннан алып терсәккә кадәр), башта уңын, аннан сулын юа.




4

Шуннан соң юеш ике учы белән башын сыпыра: маңгайдан алып баш артына кадәр һәм киресенчә, баш артыннан маңгайга кадәр;




5

Аннары юеш имән бармаклары белән колак яфракларының эчен юа;



6

Ахырда өч тапкыр аякларын ашык сөякләренә кадәр тубык тиңентен юа.



7

- Тәһарәт алуда билгеләнгән чикләрне узуга карата шәригать хөкеме?

Тәһарәт алуда билгеләнгән чикләрдән узып китеп, үзеңнән ни дә булса өстәү рөхсәт ителми, мәсәлән, тән әгъзаларын өч тапкырдан да артыграк юу, я булмаса, кулларның терсәктән югарырак өлешен юу, яки аякларны юган вакытта балтырларны юу, яки муенны сыпыру.



8

- Тәһәрәт алып бетергәннән соң :

"Әшхәду әлә иләһә иллә-Ллаһ вәхдәху лә шәрикә ләһ вәәшхәду әннә Мухәммәдән гәбдуху вә расулюх" дип әйтү тиешле. Әт-Тирмизи башка зикерләр дә китерә: "Аллахуммә-дж'әл-ни мин әт-тәввәбинә вәдж'әл-ни мин әл-мутатаххирин"

9

- ТӘҺӘРӘТНЕ БОЗУЧЫ ГАМӘЛЛӘР :

1- Женси органнардан һәм аналь ачыклыктан бүлендекләр чыгу
2- Акылны югалту: бирегә йокы һәм башкалар керә;
3- Дөя итен ашау;


10

## Тәямүм алу сыйфаты

Су булмау яки аны куллану зыян китерү сәбәпле, тән әгъзаларын чистарту мөмкинлеге булмаганда, тәһәрәтне тәяммум алмаштыра. Бу очракта су урынына туфрак кулланыла.


1

Кеше җир белән чистарыну ният кылганнан соң, "БисмиЛләһ" әйтергә, шуннан соң уч төпләре белән бер тапкыр җиргә сугарга, аннан битен һәм кул аркаларын сыпырырга тиеш.




2

һәм уч төпләре белән җиргә сукканда бармакларны берсеннән берсен аеру да, кул аркаларын сөрткәндә бармак араларын сөрту дә дөрес түгел.



3

## Гөсел алу тәртибе

Гөсел алырга ният кылу һәм пычраклардан арыну, шуннан соң "БисмиЛләһ" әйтү, бөтен тәнне, куе, шулай ук сирәк чәчләр астындагы тәнне юу, авыз һәм борыны чайкау.

1

- Гөсел тиешле булган гамәлләр :

1- Женси якынлык яки башка сәбәп белән эякуляция (мәни чыгу) булу. Шулай ук мәни чыкмыйча женси якынлык кылу да госелне боза; 2- Хәез һәм нифас каны ага башлау; 3- Үлем, бу шәһидләргә (яу кырында һәлак булучы) кагылмый; 4- Динсез кешенең Исламны кабул итүе;

2

Әзерләүче: Хәйсәм бин Мөхәммәд Джәмил Сәрхән Пәйгамбәребез мәчетендәге укытучы һәм
« mahadsunnah.com »